МИНИСТЕРСТВО ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

19.04.2022 г.Казань № 293

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2022 елның 13 маенда 9139 номеры белән теркәлде

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Аз тәэмин ителгән гаиләдән балага пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2014 елның 19 ноябрендәге 643 номерлы боерыгы белән расланган Аз тәэмин ителгән гаиләдән балага пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында

Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәте күрсәтү эшен камилләштерү максатларында б о е р ы к б и р ә м:

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Аз тәэмин ителгән гаиләдән балага пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2014 елның 19 ноябрендәге 643 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 31.07.2015 №533, 06.06.2016 №316, 28.11.2016 №668, 29.03.2017 №194, 08.06.2017 №349, 22.12.2017 №895, 07.05.2018 №351, 18.09.2018 №885, 02.04.2019 №221, 03.09.2019 №666, 14.11.2019 №1012, 06.02.2020 №71, 01.06.2020 №380, 31.12.2020 №1011, 04.05.2021 №289, 31.08.2021 №624, 01.10.2021 №714 боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Аз тәэмин ителгән гаиләдән балага пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга.

Министр Э.Ә. Зарипова

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 19.04.2022 №293 боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Аз тәэмин ителгән гаиләдән балага пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2014 елның 19 ноябрендәге 643 номерлы боерыгы белән расланган Аз тәэмин ителгән гаиләдән балага пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган үзгәрешләр

1 бүлектә:

1.2 пунктта «(законлы вәкил)» сүзләрен «яисә аны алмаштыручы зат» сүзләренә алмаштырырга;

1.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.4. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә (мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү варианты нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтүче орган үткәрә торган анкета нәтиҗәсендә билгеләнгән мөрәҗәгать итүченең тиешле билгеләренә туры килә торган дәүләт хезмәте күрсәтү) профильне яңасына үзгәртү үткәрелми.»;

1.5, 1.6 пунктларны үз көчен югалткан дип танырга;

2 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

2.1. Күрсәтелә торган дәүләт хезмәте атамасы

Аз тәэмин ителгән гаиләдән балага пособие билгеләү (алга таба – балага пособие).

2.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүче башкарма хакимият органы аталышы

2.2.1. Дәүләт хезмәте «Республикасы матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» дәүләт казна учреждениесе (алга таба – Үзәк) тарафыннан мөрәҗәгать итүченең яшәгән урыны буенча Татарстан Республикасы муниципаль районында яисә шәһәр округында Үзәк бүлекчәсендә (алга таба – Үзәк бүлекчәсе) күрсәтелә.

2.2.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү, дәүләт хезмәте күрсәтүгә гариза тапшыруны да кертеп, күпфункцияле үзәктә (алга таба – КФҮ), КФҮ ерактагы эш урыннарында гамәлгә ашырылмый.

2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе

2.3.1. Балага пособие билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар (әлеге Регламентка 3 нче кушымта нигезендәге форма буенча) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булып тора.

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе «Татарстан Республикасы халкының социаль

регистры» дәүләт мәгълүмат системасында теркәлә.

2.3.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе аны алу буенча сайланган ысул белән мөрәҗәгать итүчегә бирелә (җибәрелә):

язма рәвештә – шәхсән яки почта адресы буенча;

электрон документ формасында – электрон почта адресы һәм (яки) мөрәҗәгать итүченең Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең бердәм порталдагы, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталындагы шәхси кабинетына.

Кабул ителгән карар турында мөрәҗәгать итүчегә хәбәр телефонга смс-хәбәр итеп, электрон почта аша җибәрелергә мөмкин.

## 2.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтү чоры

2.4.1. Балага пособие билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар, әлеге Регламентның 2.6 пунктында күрсәтелгән барлык кирәкле документлар белән гариза теркәлгән көннән алып, ун эш көне эчендә кабул ителә.

2.4.2. Балага пособие билгеләү яисә билгеләүдән баш тарту турында карар кабул итү срогы, ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында соратып алына торган мәгълүматлар килмәгән очракта, 20 эш көненә озайтыла.

2.4.3. Гражданнарның керемнәре турында белешмәләргә өстәмә тикшерү үткәрелгән очракта, балага пособие билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар әлеге тикшерүдән соң, әмма барлык кирәкле документлар белән гариза теркәлгәннән соң 30 календарь көненнән дә соңга калмыйча, кабул ителә.

2.4.4. Мөрәҗәгать итүчеләрнең Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар һәм җыемнар буенча бурычлары булган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтү бурычларны түләгәнчегә кадәр туктатыла, ләкин дәүләт хезмәте күрсәтүне сорап мөрәҗәгать иткән көннән алып 90 көннән дә артыграк вакытка түгел.

2.4.5. Мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү (җибәрү) балага пособие билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар кабул ителгән көннән алып бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Балага пособие билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында мөрәҗәгать итүчегә белдерү балага пособие билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар кабул ителгән көнне гамәлгә ашырыла.

Балага пособие билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар кабул итү турында хәбәр юлланган мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алу өчен шәхсән мөрәҗәгать иткән очракта, балага пособие билгеләү (билгеләүдән баш тарту турында) карар күчермәсен бирү мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла.

## 2.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен хокукый нигезләр

Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең (функцияләрнең) бердәм порталында, «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы» дәүләт мәгълүмат системасында (алга таба – Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы) түбәндәгеләр урнаштырылган:

дәүләт хезмәте күрсәтүне җайга салучы норматив хокукый актлар исемлеге;

дәүләт хезмәте күрсәтүне тикшереп тору өчен җаваплы органнар

(учреждениеләр) һәм вазыйфаи затлар турында белешмәләр;

дәүләт хезмәтләрне күрсәтүче органнарның, шулай ук аларның вазыйфаи затларының, дәүләт яки муниципаль хезмәткәрләрнең, хезмәткәрләрнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат.

2.6. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның тулы исемлеге

2.6.1. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан шәхсән тапшырыла торган, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар:

1) банкта яки башка кредит оешмасында законнарда билгеләнгән тәртиптә социаль түләүләрне күчерү өчен ачылган шәхси счет реквизитларын (балага пособиене банк яки башка кредит оешмасы аша алган очракта) күрсәтеп, балага пособие билгеләү турында гариза:

әлеге Регламентка 1 нче кушымта нигезендәге форма буенча кәгазь документ рәвешендә;

Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы һәм Бердәм портал аша мөрәҗәгать иткәндә, электрон формада (Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында һәм Бердәм порталда, гаризаны нинди дә булса башка төрле формада өстәмә тапшыру зарурлыгыннан башка гына) интерактив форманы тутыру юлы белән), әлеге пункт таләпләре нигезендә имзалап;

2) баланың тууын теркәү турындагы таныклыкның чит дәүләтнең компетентлы органы тарафыннан бирелгән күчермәсе һәм аның нотариаль яктан расланган рус теленә тәрҗемә күчермәсе;

3) чит ил дәүләтенең компетентлы органы тарафыннан бирелгән гаилә коруны теркәү турында таныклык күчермәсе һәм аның нотариаль яктан расланган рус теленә тәрҗемәсе;

4) аерылышу турында чит дәүләтнең компетентлы органы тарафыннан бирелгән таныклык күчермәсе һәм аның нотариаль яктан расланган рус теленә тәрҗемәсе;

5) чит ил дәүләтенең компетентлы органы тарафыннан бирелгән вафат булуны теркәү турында таныклык күчермәсен һәм аның нотариаль яктан расланган рус теленә тәрҗемәсе;

6) гражданлык хәле актларын теркәү органнары яисә Россия Федерациясе консуллык учреждениеләре тарафыннан бирелгән уллыкка алу турында таныклык күчермәсе;

7) мөрәҗәгать итүченең һәм аның гаилә әгъзаларының гариза тапшырылган айга кадәр алты календарь аеннан алда килгән соңгы 12 календарь ае өчен керемнәрен раслый торган документлар:

һөнәри белем бирү оешмаларында һәм югары белем бирү оешмаларында укучыларга, фәнни-педагогик кадрлар әзерләү программалары буенча көндезге формада белем алучы аспирантларга һәм югары белем бирүче мәгариф оешмаларының һәм фәнни оешмаларның дини белем бирү оешмаларында укучы дикторантларга түләнә торган стипендияләр һәм матди ярдәм турында белешмә;

гаилә әгъзалары ала торган алиментлар турында белешмә;

8)чит ил дәүләте территориясендә бирелгән Россия Федерациясеннән читтә белем алу турында документ күчермәсен һәм гомуми белем бирү оешмасында белем ала торган 16 яшьтән олырак бала өчен әлеге документның нотариаль таныкланган рус теленә тәрҗемәсен;

9) Күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестрында хокуклары теркәлмәгән, гаилә әгъзалары милкендә булган күчемсез милек объектларына хокук билгели торган документларның күчермәләре;

10) әлеге Регламентның 1.2 пунктында күрсәтелгән гражданнарның гаилә составына Россия Федерациясе Торак кодексының 51 статьясындагы 1 өлешенең 4 пунктында каралган исемлектә күрсәтелгән хроник авыруның катлаулы формасыннан интегүче затлар кергән очракта, мондый авыру белән законнар нигезендә бергә яшәве мөмкин булмаган очракта, гаилә әгъзасында Россия Федерациясе Торак кодексының 51 статьясындагы 1 өлешенең 4 пунктында каралган исемлектә күрсәтелгән, законнар нигезендә бергә яшәү мөмкинлеген бирми торган хроник авыруның катлаулы формасы булуы турында белешмә;

11) ялгыз ана балага пособие алу өчен мөрәҗәгать иткән затлар өстәмә рәвештә ГХАТ органнарыннан баланың атасы турында белешмәләрне туу турында таныклыкка кертү нигезе турында белешмә тапшыра;

12) чакыру буенча хәрби хезмәт уза торган хәрби хезмәткәрнең баласына пособие алу өчен мөрәҗәгать итүче зат өстәмә рәвештә баланың атасын хәрби хезмәткә чакыру турында хәрби комиссариаттан белешмә яки баланың атасының белем алуы турында һөнәри белем бирүче хәрби белем бирү йортыннан белешмә тапшыра;

13) бурычлы затның даими яшәү өчен чит илгә китүе турында белешмә;

14) тулысынча дәүләт тәэминатында тору турында документ;

15) иренең мәҗбүри дәвалануда булуы турында документ;

16) башка керемнәрне алу турында раслый торган документлар.

Мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткәндә шәхесен таныклаучы документны күрсәтә.

Аны алмаштыра торган зат (законнарда каралган очракларда) яисә мөрәҗәгать итүче тарафыннан вәкаләт бирелгән затлар мөрәҗәгать итүче мәнфәгатьләрендә эш итүләрен раслый торган документны күрсәтә.

Гариза Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы, Бердәм портал аша җибәрелгән очракта, мөрәҗәгать итүченең яки аның законлы вәкиленең шәхесен таныклый торган документындагы белешмәләре исәпкә алыну язуы Бердәм идентификация һәм аутентификация системасында (алга таба – ИАБС) расланган вакытта тикшерелә.

Мөрәҗәгать итүченең законлы вәкиленең вәкаләтләрен раслый торган, юридик зат тарафыннан бирелгән документ документны биргән вәкаләтле затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган булырга тиеш.

Мөрәҗәгать итүченең законлы вәкиленең вәкаләтләрен раслый торган, шәхси эшкуар тарафыннан бирелгән документ шәхси эшкуарның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган булырга тиеш.

Мөрәҗәгать итүченең законлы вәкиленең вәкаләтләрен раслый торган, нотариус тарафыннан бирелгән документ нотариусның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган булырга тиеш. Башка очракларда – гади электрон

имза белән имзаланган булырга тиеш.

Документлар һәм белешмәләр мөрәҗәгать итүче тарафыннан тиешле оешмаларда – турыдан-туры, шул исәптән, мондый мөмкинлек булган очракта, электрон рәвештә алына.

Документларның күчермәләре, әгәр алар Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган булса, төп нөсхәләре белән бергә күрсәтелә һәм Үзәк бүлекчәсе белгече тарафыннан таныклана.

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен гариза бланкын мөрәҗәгать итүче Үзәк бүлекчәсенә шәхсән мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Бланкның электрон формасы «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының (алга таба – Министрлык) рәсми сайтында http://mtsz.tatarstan.ru урнаштырылган.

Гариза һәм аңа теркәлә торган документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан Үзәк бүлекчәсенә түбәндәге ысулларның берсе буенча тапшырыла (җибәрелә) ала:

1) шәхсән яисә почта аша кәгазьдә;

2) Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында, Бердәм порталда гаризаның электрон формасын тутыру юлы белән Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы, Бердәм портал аша электрон формада;

3) гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләре, шул исәптән Интернет челтәре аша.

Гаризаны почта аша җибәргәндә аңа теркәлә торган документларның күчермәләре (шәхесне таныклый торган документ күчермәсеннән кала) Россия Федерациясе законнары нигезендә таныкланган булырга тиеш.

Мөрәҗәгать итүче гаризаны һәм кирәкле документларны Бердәм портал, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша җибәргән очракта, гаризаны гади электрон имза белән имзалый.

Гади электрон имзаны алу өчен, мөрәҗәгать итүчегә ИАБС системасында теркәлү (аутентификация) процедурасын узарга, шулай ук стандарттан ким булмаган дәрәҗәгә кадәр исәпкә алу язуын расларга кирәк.

2.6.2. Ведомствоара хезмәттәшлек каналлары буенча вәкаләтле органнардан түбәндәге белешмәләр алына:

мөрәҗәгать итүче белән аның яшәү урыны буенча теркәлгән гражданнар турында;

опека (химаяче) билгеләү һәм опекунның (химаяченең) баланы асрауга акча алуы турында;

балага пособие билгеләү турындагы мәсьәләне хәл иткәндә исәпкә алына торган физик затларның керемнәре турында;

бала тууны дәүләт теркәвенә алу турында;

өйләнешүне (аерылышуны) дәүләт теркәвенә алу турында;

вафат булуны дәүләт теркәвенә алу турында;

баланы тәрбиягә алучы гаиләгә тапшыру һәм тәрбиягә алучы ата-аналарга тиешле түләү суммалары турында;

ата-ана хокукыннан мәхрүм ителү турында яисә ата-ана хокукында чикләнү турында;

күчемсез мөлкәт булуы турында;

транспорт чаралары, үзйөрешле транспорт чаралары һәм башка төр техникасы булуы турында;

билгеләнгән тәртиптә торак урынын яшәү өчен яраксыз дип тану турында;

Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар һәм җыемнар буенча бурычлар булу (булмау) турында;

шәхси счетның иминият номеры турында;

баланың (балаларның) гомуми белем бирү оешмасында белем алуы турында;

әҗәте булган затның иректән мәхрүм итү, арест астында тору, мәҗбүри дәвалануда булу рәвешендә җәза үтүгә бәйле рәвештә алимент түләттерелә алмый торган затның кереме булмавы турында;

алимент түләүдән читләшү сәбәпле, ата-аналарны эзләтү турында;

җинаять кылган өчен ата-аналарны җинаять җаваплылыгына тарту турында;

вәкилнең вәкаләтләрен раслый торган документ турында;

паспортның чын булуын тикшерү турында;

фамилия-исем төркемнәренең, туу датасының, җенеснең һәм СНИЛС туры килүе турында;

18 яше тулмаган инвалид баланы яки балачактан ук I төркем инвалидны яки хезмәткә сәләтсез затларны карый торган затлар турында;

мөрәҗәгать итүченең яки аның гаилә әгъзаларының иректән мәхрүм итү урыныннан чыгарылуы турында;

мөрәҗәгать итүченең һәм гаилә әгъзаларының ИНН турында;

«Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын куллану кысаларында алынган керемнәр күләме турында;

Россия Федерациясе субъекты тарафыннан билгеләнгән чорда элегрәк алынган түләү турында;

ата-ананың икенчесенең түләүне алмавы турында;

фамилия, исем, ата исеменең үзгәрүе турында.

Мөрәҗәгать итүче Бердәм портал, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша мөрәҗәгать иткән очракта, мөрәҗәгать итүче паспортының чын булуын раслау турындагы белешмәләр ведомствоара хезмәттәшлек каналлары буенча өстәмә рәвештә алына.

Мөрәҗәгать итүче югарыда аталган белешмәләрне раслый торган документларны үз инициативасы белән дә тапшырырга хокуклы.

Әлеге документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан турыдан-туры вәкаләтле оешмалардан алынырга мөмкин, шул исәптән, мондый мөмкинлек булганда, электрон формада да, һәм әлеге пунктта каралган документларны тапшыру өчен әлеге Регламентта каралган тәртиптә тапшырылырга мөмкин.

Мөрәҗәгать итүченең югарыда күрсәтелгән документларны тапшырмавы мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигез була алмый.

## 2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларны кабул итүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге

2.7.1. Документларны кабул итүдән баш тарту нигезләре:

документларда бетерелгән, өстәп язылган урыннарның, сызылган сүзләрнең һәм төзәтмәләрнең Россия Федерациясе законнары нигезендә танылмаган булуы;

63-ФЗ номерлы Федераль законның 11 статьясында билгеләнгән квалификацияле электрон имзаның чынлыгын тану шартларының үтәлмәве;

күчермәләре Россия Федерациясе законнары нигезендә таныкланмаган очракта, мөрәҗәгать итүче тарафыннан шәхсән мөрәҗәгать иткәндә төп документларның күрсәтелмәве;

мөрәҗәгать итүченең документларның Россия Федерациясе законнары нигезендә таныкланмаган күчермәләрен почта аша җибәрүе;

мөрәҗәгать итүченең яисә мөрәҗәгать итүче исеменнән ышаныч кәгазе нигезендә эш итәргә вәкаләтле затның мөрәҗәгать итүченең яшәгән урынына карамаган Үзәк бүлекчәсенә мөрәҗәгать итүе;

хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларның тулы булмаган комплект белән тапшырылуы;

документларда хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларда булган мәгълүматны һәм белешмәләрне тулы күләмендә файдалану мөмкинлеген бирми торган бозык урыннар булуы;

дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаның һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның билгеләнгән таләпләрне бозып, электрон формада тапшырылуы.

2.7.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гариза һәм башка документлар Бердәм порталда, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында, Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырылган, дәүләт хезмәте күрсәтү сроклары һәм тәртибе турындагы мәгълүматка туры китереп тапшырылган булсалар, гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле башка документларны кабул итүдән баш тарту тыела.

## 2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге

2.8.1. Мөрәҗәгать итүченең Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар буенча бурычы булуы дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен нигез булып тора.

2.8.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләре:

әлеге Регламентның 2.6.1 пунктында күрсәтелгән документларның тапшырылмавы, әлеге Регламентның 2.6.1 пунктның 7 пунктчасында күрсәтелгән, бердәнбер ата-анага карата документлардан тыш, аның кереме булмаган очракта яки ата-аналарның берсенә карата, әгәр аның керемнәре булмаса һәм ата-ананың икенчесе хезмәт эшчәнлеген башкарса яисә пенсионер булып торса яки инвалид бала караучы зат булса (яки I төркем инвалид яки дәвалау учреждениесе бәяләмәсе буенча даими рәвештә ятлар каравына мохтаҗ дип танылган өлкән яшьтәге яки 80 яшенә җиткән зат булса) яисә 18 яшенә кадәр биш һәм аннан күбрәк баласы булган, билгеләнгән тәртиптә эшсез дип танылган булса;

мөрәҗәгать итүченең Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар һәм җыемнар буенча бурычлары балага пособие билгеләү турында сорап мөрәҗәгать иткән көннән соң 90 көн эчендә җайга салынмаган булса;

мөрәҗәгать итүче гаиләсенең мөлкәти тәэмин ителеш дәрәҗәсенең «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8

декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына кушымтада билгеләнгән мөлкәти тәэмин ителеш дәрәҗәсеннән артып китүе;

гаиләнең җан башына исәпләгәндә уртача керем күләменең балага пособие билгеләү өчен мөрәҗәгать итү датасына Татарстан Республикасында билгеләнгән яшәү минимумы күләмен арттырып җибәрүе;

мөрәҗәгать итүченең яисә аның хезмәткә сәләтле гаилә әгъзаларының керемнәре булмау, 18 яшькә кадәрле биш һәм аннан күбрәк баласы булган күпбалалы гаиләләрдән бердәнбер ата-ананың яки ата-ананың берсенең керемнәре булмаган очрактан тыш, ата-ананың икенчесе хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашыруы яисә пенсионер яки инвалид баланы (яки I төркем инвалидны яки дәвалау оешмасы бәяләмәсе буенча даими рәвештә ятлар каравына мохтаҗ булган яисә 80 яшенә җиткән өлкән кешене) карый торган зат, яки билгеләнгән тәртиптә эшсез дип танылган зат булып торуы шарты белән;

әгәр бала (балалар) тулысынча дәүләт тәэминатында булса, Россия Федерациясе гражданнарының, чит ил гражданнарының һәм гражданлыгы булмаган затларның мөрәҗәгать итүе;

ата-ана хокукыннан мәхрүм ителгән яисә ата-ана хокуклары чикләнгән Россия Федерациясе гражданнарының, чит ил гражданнарының һәм гражданлыгы булмаган затларның мөрәҗәгать итүе;

әгәр бала опекада (попечительлектә) торса һәм опекун (попечитель) аны карап тоту өчен акча алса;

әгәр 18 яшькә кадәрге бала өйләнешү аркасында яки аның эмансипациясе белән бәйле рәвештә, эшкә хокук алган булса;

әгәр балага пособие сорап мөрәҗәгать иткән ата-анага карата алимент йөкләмәләре барлыкка килгән булса;

шушы Регламентның 1.2 пунктында күрсәтелмәгән затның документлар белән мөрәҗәгать итүе;

ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында алынган мәгълүматларга каршы килә торган мәгълүматларның һәм (яки) документларның тапшырылуы.

2.8.3. Әгәр дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза дәүләт хезмәте күрсәтү сроклары һәм тәртибе турында Бердәм порталда, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында, Министрлыкның рәсми сайтында бастырып чыгарылган мәгълүмат нигезендә тапшырылган булса, дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту тыела.

## 2.9. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән алына торган түләү күләме һәм аны алу ысуллары

Дәүләт хезмәте түләүсез нигездә күрсәтелә.

## 2.10. Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы рәсми мөрәҗәгатьне тапшырганда яисә мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәләрен алганда чират көтүнең максималь вакыты

2.10.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаны тапшырганда һәм дәүләт

хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алганда чират көтүнең максималь вакыты – 15 минуттан артык түгел.

2.10.2. Мөрәҗәгать итүчеләрнең аерым категорияләре өчен чират билгеләнмәгән.

### 2.11. Мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтү турында мөрәҗәгатен теркәүгә алу чоры

2.11.1. Гариза һәм документлар кергән көннән башлап бер көн эчендә

2.11.2. Ял (бәйрәм) көнендә электрон рәвештә килгән гариза ял (бәйрәм) көненнән соңгы эш көнендә теркәлә.

### 2.12. Дәүләт хезмәтләре күрсәтелә торган биналарга карата таләпләр

2.12.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән тәэмин ителгән биналарда гамәлгә ашырыла.

2.12.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүмат мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып, урнаштырыла. Көтү залларында (бүлмәләрдә) мәгълүматлар, шулай ук аларны тутыру үрнәкләре белән дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза формалары урнаштырылган мәгълүмат стендлары урнаштырыла.

2.12.3. Инвалидларга дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектларда (алга таба – объект) законнар һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән таләпләргә туры китереп, түбәндәге уңайлы шартлар тудырыла:

а) объектларга каршылыксыз керү һәм чыгу мөмкинлеге;

б) дәүләт хезмәте күрсәтелә торган урынга үтеп керү максатларында, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтә торган объект хезмәткәрләре, ассистив һәм ярдәмче технологияләр, шулай ук алмаштырыла торган кресло-коляска ярдәмендә дә, объект территориясе буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү мөмкинлеге;

в) объектка керә торган урында транспорт чарасына утыру һәм аннан төшү мөмкинлеге, шул исәптән кресло-коляска кулланып һәм, кирәк булганда, хезмәт күрсәтүче хезмәткәрләр ярдәмендә дә;

г) күрү һәм мөстәкыйль хәрәкәт итү буенча тотрыклы җитешсезлекләре булган инвалидларга объект территориясе буйлап хәрәкәт итәргә булышу;

д) инвалидка объектка кергәндә һәм аннан чыкканда ярдәм итү, инвалидка җәмәгать транспортының уңайлы маршрутлары турында мәгълүмат бирү;

е) инвалидларның объекттан һәм дәүләт хезмәтеннән каршылыксыз файдалана алуын тәэмин итү өчен, алар яшәешендәге чикләүләрне исәпкә алып, кирәкле мәгълүмат чараларын тиешенчә урнаштыру, шул исәптән дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәкле тавышлы һәм күрсәтмә мәгълүматларны, шулай ук язуларны, тамгаларны һәм текстлы башка төрле һәм Брайльнең рельефлы-ноктaлы хәрефләре белән һәм контраст фонда башкарылган тамгалардан график мәгълүматны кабатлау;

ж) Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Сукырларны йөртүче этнең махсус өйрәтелгән булуын раслаучы документ рәвешен

һәм аны бирү тәртибен раслау турында» 2015 елның 22 июнендәге 386н номерлы боерыгы белән расланган рәвештә һәм тәртиптә бирелә торган һәм аның махсус рәвештә өйрәтелгән булуын раслаучы документы булган очракта, объектка озата йөри торган этне кертү.

2.12.4. Инвалидларга законнарда һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән таләпләргә туры китереп, дәүләт хезмәтеннән файдалану алу мөмкинлеге бирү өчен түбәндәге уңайлы шартлар тудырыла:

а) инвалидларга дәүләт хезмәте күрсәтү кагыйдәләре турында, шул исәптән дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү турында, дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәкле башка гамәлләрне башкару турында кирәкле ярдәмне күрсәтү;

б) ишетү буенча инвалидларга, кирәк булганда, рус ишарә теленнән файдаланып, сурдотәрҗемәчене, тифлосурдотәрҗемәчене объектка кертүне дә исәпкә алып, дәүләт хезмәте күрсәтү;

в) инвалидларга башка затлар белән бертигез рәвештә дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен комачау иткән каршылыкларны бетерүдә кирәкле башка ярдәмне күрсәтү;

г) дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында (шул исәптән мәгълүмат стендында да) Брайльнең рельефлы-ноктал хәрефләре белән һәм контрастлы фонда башкарылган документлар, белдерүләр, күрсәтмә аңлатмалар, шулай ук аудиоконтур күчермәләре булу.

2.12.5. 2016 елның 1 июленнән соң реконструкция, модернизация үткән, файдалануга тапшырылган объектларга һәм чараларга карата дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектларның инвалидлар өчен файдалана алырлык булуын тәэмин итү өлешендәге таләпләр.

## 2.13. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең мөмкинлекле һәм сыйфатлы булу күрсәткечләре

2.13.1. Дәүләт хезмәтенең һәркемгә күрсәтелә алырлык булуы күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

Үзәк бүлекчәсе бүлмәләренең җәмәгать транспортыннан файдалану мөмкинлеге булган зонада урнашуы;

инвалидларга башка затлар белән бертигез дәрәҗәдә хезмәтләрдән файдалануга комачау итүче каршылыкларны җиңәргә ярдәм күрсәтелүе;

белгечләрнең, шулай ук мөрәҗәгать итүчеләрдән документлар кабул ителә торган урыннарның да, кирәкле санда булуы;

мәгълүмат Үзәк бүлекчәсе стендларында, «Интернет» челтәрендә, Министрлыкның рәсми сайтында дәүләт хезмәте күрсәтү ысуллары, тәртибе, вакытлары турында тулы мәгълүмат булуы;

электрон рәвештә гариза тапшыру мөмкинлеге;

хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен мөрәҗәгать итүченең Республика порталындагы шәхси кабинеты аша электрон рәвештә алу мөмкинлеге.

2.13.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турында мәгълүмат мөрәҗәгать итүче тарафыннан Министрлыкның рәсми сайтында, Бердәм порталда, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында

(http://uslugi.tatarstan.ru/) алынырга мөмкин.

2.13.3. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфатлы булу күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

документларны кабул итү һәм карау чорларының саклануы;

дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алу чорының саклануы;

Үзәк бүлекчәсе белгечләренең әлеге Регламентны бозуына нигезле шикаятьләрнең булмавы.

2.13.4. мөрәҗәгать итүченең Үзәк бүлекчәсе белгечләре белән үзара хезмәттәшлеге:

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларны турыдан-туры тапшырганда – бер мәртәбәдән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча);

гариза һәм документларны почта (электрон почта) аша җибәргәндә, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы яки Татарстан Республикасы Электрон Хөкүмәте инфоматлары аша җибәргәндә, турыдан-туры бәйләнешкә керү таләп ителми.

2.13.5. Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә мөрәҗәгать итүченең Үзәк бүлекчәсе белгече белән бер мәртәбә бәйләнешкә керү вакыты 15 минуттан артмый.

2.13.6. Экстерриториаль принцип буенча һәм комплекслы мөрәҗәгать составында дәүләт хезмәте күрсәтелми.

2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтүгә башка таләпләр, шул исәптән: күпфункцияле үзәкләрдә дәүләт хезмәте күрсәтүнең үзенчәлекләрен һәм электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә ала торган; Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә дәүләт хезмәте турында белешмәләр бирү турында

2.14.1. Дәүләт хезмәтен экстерриториаль принцип буенча күрсәтү гаризаларны Бердәм портал, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша җибәрү мөмкинлеген тәэмин итү өлешендә гамәлгә ашырыла.

КФҮ аша дәүләт хезмәте күрсәтүгә гариза бирүне дә кертеп, дәүләт хезмәте күрсәтү КФҮ, КФҮнең ерактагы эш урыннарында гамәлгә ашырылмый.

2.14.2. Электрон формада дәүләт хезмәте күрсәткәндә мөрәҗәгать итүче хокуклы:

а) дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында Бердәм порталда һәм Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында урнаштырылган мәгълүматны алырга;

б) дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле башка документларны, шул исәптән электрон үрнәкләре элегрәк «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законның (алга таба – 210-ФЗ номерлы федераль закон) 16 статьясының 1 өлешендәге $7^2$ пункты нигезендә таныкланган документларны һәм мәгълүматны Бердәм порталдан, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталыннан файдаланып тапшырырга;

в) электрон формада тапшырылган дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаларны үтәү барышы турында белешмәләр алырга;

г) Бердәм портал, Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфатын бәяләргә;

д) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен электрон документ формасында алырга;

е) Бердәм портал, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган органнар, аларның вазыйфаи затлары, дәүләт һәм муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтелгәндә кабул ителгән карарларга һәм кылынган гамәлләргә (гамәл кылмауга) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү процессын тәэмин итә торган федераль дәүләт мәгълүмат системасы порталы ярдәмендә Үзәк, шулай ук аның вазыйфаи затлары, дәүләт хезмәткәрләре карарына һәм гамәленә (гамәл кылмавына) шикаять бирергә.

2.14.3. Гаризаны формалаштыру, гаризаны өстәмә рәвештә нинди дә булса башка формада тапшыру зарурлыгыннан тыш, Бердәм порталда, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында гаризаның электрон формасын тутыру юлы белән гамәлгә ашырыла. Бу очракта мөрәҗәгать итүче яки аның законлы вәкиле Бердәм порталда, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында ИАБС системасында исәпкә алыну язуын раслау юлы белән авторизация уза, электрон рәвештә интерактив формадан файдаланып, дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаны тутыра.

Дәүләт хезмәте күрсәтү турында тутырылган гариза, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның электрон рәвешләрен теркәп, мөрәҗәгать итүче тарафыннан Үзәк бүлекчәсенә җибәрелә. ИАБС системасында авторизацияләнгән очракта, дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза мөрәҗәгать итүченең, гаризаны имзалау өчен вәкаләтле мөрәҗәгать итүче вәкиленең гади электрон имзасы белән имзаланган дип санала.

Гариза Бердәм портал, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша җибәрелгән очракта, әлеге Регламентның 2.3 пунктында күрсәтелгән дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе мөрәҗәгать итүчегә, мөрәҗәгать итүченең вәкиленә Бердәм порталда, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында шәхси кабинетка Үзәк бүлекчәсе җитәкчесенең көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән таныкланган электрон документ формасында җибәрелә.

2.14.4. Электрон документлар түбәндәге форматларда тапшырыла:

а) xml - формалаштырылган документлар өчен;

б) doc, docx, odt - формулалары булмаган, текстлы эчтәлектәге документлар өчен (әлеге пунктның «в» пунктчасында күрсәтелгән документлардан тыш);

в) xls, xlsx, ods - исәпләмәләре булган документлар өчен;

г) pdf, jpg, jpeg - формулаларны һәм (яки) график сурәтләрне дә үз эченә алган (әлеге пунктның «в» пунктчасында күрсәтелгән документлардан тыш), шулай ук график сурәтләре булган документларны да кертеп, текстлы эчтәлектәге документлар өчен.

Документның үз оригиналын сканер аша уздыру юлы белән электрон документны формалаштыру рөхсәт ителә (күчермәләрне куллану рөхсәт ителми), ул 300 - 500 dpi (масштаб 1:1) мөмкинлегендә документ оригиналы ориентациясен саклап гамәлгә ашырыла, түбәндәге режимнарны кулланып:

«каралы-аклы» (документта график сурәтләр һәм (яки) төсле текст булмаган очракта);

«соры төсмерләрдә» (документта төсле график сурәтләрдән аерыла торган

график сурәтләр булган очракта);

«төсле» яки «төсне тулы дәрәҗәсендә тапшыру режимы» (документта төсле график сурәтләр яисә төсле текст булган очракта);

чын нөсхәдәге барлык аутентик билгеләрне, атап әйткәндә: затның график имзасын, мөһерне, бланк чатындагы штампны саклап;

файллар саны һәркайсында текстлы һәм (яки) графикалы мәгълүматлар булган документлар санына туры килергә тиеш.

Электрон документлар түбәндәгеләрне тәэмин итәргә тиеш:

документны һәм документтагы битләр санын идентификацияләү мөмкинлеген;

өлешләргә, бүлекләргә, кисәкләргә (кискәчләргә) бүленгән документлар өчен эчтәлек буенча һәм (яки) текстта булган рәсемнәргә һәм таблицаларга күчү мөмкинлеген.

xls, xlsx яки ods форматларында тапшырылырга тиешле документлар аерым электрон документ рәвешендә формалаштырыла.

2.14.5. Мөрәҗәгать итүчеләрне Үзәк бүлекчәсенә кабул итүгә язу (алга таба – кабул итүгә язу) Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы, Үзәк бүлекчәсе телефоны аша гамәлгә ашырыла.

Мөрәҗәгать итүчегә Үзәктә билгеләнгән кабул итү графигы чикләрендә теләсә нинди буш кабул итү датасына һәм вакытына язылу мөмкинлеге бирелә.

Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша алдан язылуны гамәлгә ашыру өчен, мөрәҗәгать итүчегә система аша соралган мәгълүматларны күрсәтергә кирәк, шул исәптән:

фамилиясен, исемен һәм атасының исемен (булган очракта);

телефон номерын;

электрон почта адресын (ихтыярына карап);

кабул итүнең теләнгән датасын һәм вакытын.

Кабул итүгә алдан язылган очракта, мөрәҗәгать итүче күрсәткән белешмәләр мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә кабул иткәндә тапшырылган документларга туры килмәгән очракта, алдан язылу гамәлдән чыгарыла.

Кабул итүгә алдан язылган очракта, мөрәҗәгать итүчегә талон-раслама чыгартып алу мөмкинлеге бирелә. Әгәр мөрәҗәгать итүче электрон почта адресын күрсәтсә, күрсәтелгән адреска шулай ук кабул итү датасын, вакытын һәм урынын күрсәтеп, алдан язылуны раслау турында мәгълүмат җибәрелә.

Кабул итүгә алдан язылган вакытта билгеләнгән кабул итү вакыты башланып, 15 минут узганнан соң да килмәгән очракта, мөрәҗәгать итүчегә алдан язылуның гамәлдән чыгарылуы турында зарури тәртиптә мәгълүмат җиткерелә.

Мөрәҗәгать итүче теләсә кайсы вакытта алдан язылудан баш тарта ала. Россия Федерациясе норматив хокукый актлары нигезендә идентификацияләүне һәм аутентификацияләүне узудан, кабул итү максатын күрсәтүдән, шулай ук кабул итү өчен алдан ук билгеләп куелырга тиешле кирәкле вакыт озынлыгын исәпләүдә кирәкле белешмәләрне тапшырудан тыш, мөрәҗәгать итүчедән башка гамәлләр башкаруны таләп итү тыела.

2.14.6. Гариза Бердәм портал, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша җибәрелергә мөмкин.

Бердәм портал, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы гариза биргәндә, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе электрон формада

бирелә.

2.14.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында мәгълүмат Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә урнаштырыла.

2.14.8. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр күрсәтү таләп ителми.

2.14.9. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә кулланыла:

«Татарстан Республикасы халкының социаль регистры» дәүләт мәгълүмат системасы;

«Ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасы;»;

3 нче бүлектә:

Исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм чорлары»;

3.3.1 пунктта:

беренче абзацта «2.5» саннарын «2.6.1» саннарына алмаштырырга;

унберенче абзацта «2.5» саннарын «2.6.1» саннарына алмаштырырга;

уналтынчы абзацта «2.5» саннарын «2.6.1» саннарына алмаштырырга;

3.4.2 пунктны киләсе редакциядә бәян итәргә:

3.4.2. Балага пособие билгеләү турында карар кабул итү өчен кирәкле белешмәләр Үзәк бүлекчәсендә булмаган очракта, Үзәк бүлекчәсе белгече ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек системасы ярдәмендә түбәндәге белешмәләрне бирү турында электрон рәвештә рәсми мөрәҗәгатьләр җибәрә:

мөрәҗәгать итүче белән аның яшәү урыны буенча теркәлгән гражданнар турында;

опека (химаяче) билгеләү һәм опекунның (химаяченең) баланы асрауга акча алуы турында;

балага айлык пособие билгеләү турындагы мәсьәләне хәл иткәндә исәпкә алына торган физик затларның керемнәре турында;

бала тууны дәүләт теркәвенә алу турында;

өйләнешүне (аерылышуны) дәүләт теркәвенә алу турында;

вафат булуны дәүләт теркәвенә алу турында;

баланы тәрбиягә алучы гаиләгә тапшыру һәм тәрбиягә алучы ата-аналарга тиешле түләү суммалары турында;

ата-ана хокукыннан мәхрүм ителү турында яисә ата-ана хокукында чикләнү турында;

күчемсез мөлкәт булуы турында;

транспорт чаралары, үзйөрешле транспорт чаралары һәм башка төр техникасы булуы турында;

билгеләнгән тәртиптә торак урынын яшәү өчен яраксыз дип тану турында;

Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар һәм җыемнар буенча бурычлар булу (булмау) турында;

шәхси счетның иминият номеры турында;

баланың (балаларның) гомуми белем бирү оешмасында белем алуы турында;

әҗәте булган затның иректән мәхрүм итү, арест астында тору, мәҗбүри дәвалануда булу рәвешендә җәза үтүгә бәйле рәвештә алимент түләттерелә алмый торган затның кереме булмавы турында;

алимент түләүдән читләшү сәбәпле, ата-аналарны эзләтү турында;

җинаять кылган өчен ата-аналарны җинаять җаваплылыгына тарту турында;

вәкилнең вәкаләтләрен раслый торган документ турында;

паспортның чын булуын тикшерү турында;

фамилия-исем төркемнәренең, туу датасының, җенеснең һәм СНИЛС туры килүе турында;

18 яше тулмаган инвалид баланы яки балачактан ук I төркем инвалидны яки хезмәткә сәләтсез затларны карый торган затлар турында;

мөрәҗәгать итүченең яки аның гаилә әгъзаларының иректән мәхрүм итү урыныннан чыгарылуы турында;

мөрәҗәгать итүченең һәм гаилә әгъзаларының ИНН турында;

«Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын куллану кысаларында алынган керемнәр күләме турында;

Россия Федерациясе субъекты тарафыннан билгеләнгән чорда элегрәк алынган түләү турында;

ата-ананың икенчесенең түләүне алмавы турында;

фамилия, исем, ата исеменең үзгәрүе турында.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гариза һәм документларны кабул итү һәм теркәү көнендә гамәлгә ашырыла. Вәкаләтле орган ведомствоара гаризаларны карый һәм законнарда билгеләнгән срокларда җавап җибәрә.

Процедураның нәтиҗәсе: белешмәләр бирү турында рәсми мөрәҗәгать.»;

3.5.4.1 пунктында:

беренче абзацта «салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча» сүзләрен «салымнар һәм җыемнар буенча» сүзләренә алмаштырырга;

бишенче абзацта «салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча» сүзләрен «салымнар һәм җыемнар буенча» сүзләренә алмаштырырга;

3.5.4.2 пунктының беренче абзацында «салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча» сүзләрен «салымнар һәм җыемнар буенча» сүзләренә алмаштырырга;

4 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Административ регламент үтәлешен контрольдә тоту формалары

4.1. Әлеге Регламентның административ процедураларында билгеләнгән гамәлләр эзлеклелеген үтәүне агымдагы контрольдә тоту Үзәк җитәкчесе тарафыннан әлеге Регламентның нигезләмәләрен саклау һәм үтәү буенча тикшерүләр үткәрү юлы белән гамәлгә ашырыла. Үзәк бүлекчәсе җитәкчесе тарафыннан карарлар кабул ителүне көндәлек тикшереп торуны оештыру тәртибен һәм рәвешләрен Үзәк директоры билгели.

Агымдагы тикшереп тору даими нигездә гамәлгә ашырыла.

4.2. Әлеге Регламент үтәлешен контрольдә тоту әлеге контрольне гамәлгә ашыруга вәкаләтле Министрлык Аппараты бүлегенең һәм Татарстан Республикасы муниципаль районында һәм шәһәр округында Министрлыкның социаль яклау идарәсенең (бүлегенең) вазыйфаи затлары тарафыннан гамәлгә ашырыла, аларның вәкаләтләре Министрлыкның структур бүлекчәсе турындагы нигезләмәдә һәм хезмәткәрләрнең вазыйфаи регламентлары белән билгеләнә.

4.3. Әлеге Регламент үтәлешен контрольдә тоту дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы вазыйфаи затларның гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаятьләр булган

мөрәҗәгатьләргә тикшерүләр үткәрүне, карарлар кабул итүне, җаваплар әзерләүне үз эченә ала.

Административ процедуралар үтәлешен тикшереп тору рәвешләре түбәндәгеләргә карата тикшерүләр уздырудан гыйбарәт:

эшнең алып барылуына;

документларны карау нәтиҗәләренең законнардагы (шушы Регламенттагы) таләпләргә туры килүенә;

документларны кабул итүнең чорлары һәм тәртибе саклануга;

дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә нәтиҗәләр тапшыру чорлары һәм тәртибе саклануга.

Тикшерүләрне үткәрү ешлыгы планлы характерга (эш планнары нигезендә гамәлгә ашырыла) һәм планнан тыш характерга (мөрәҗәгать итүченең конкрет мөрәҗәгате буенча) ия.

4.4. Әлеге Регламент үтәлешенә планнан тыш тикшерү уздыру турындагы карар түбәндәге очракларда кабул ителә:

1) әлеге Регламенттагы һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә таләпләр билгеле торган норматив хокукый актлардагы таләпләрне бозуның элек ачыкланган очракларын юкка чыгаруны тикшерүгә бәйле рәвештә;

2) мөрәҗәгать итүчеләр Министрлыкның дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган вазыйфаи затлары гамәлләренең (гамәл кылмавының) үзләренең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен бозуга бәйле шикаятьләр белән мөрәҗәгать иткәндә.

4.5. Үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәләре буенча мөрәҗәгать итүчеләрнең хокукларын бозу очраклары ачыкланган очракта, әлеге административ регламентны үтәү өчен җаваплы булып, гаепле дип танылган вазыйфаи затлар Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә җаваплылыкка тартыла.

4.6. Әлеге Регламент үтәлешен контрольдә тоту гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә Үзәк, Үзәк бүлекчәсе эшчәнлегенең ачыклыгы, дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында тулы, актуаль һәм ышанычлы мәгълүмат алу һәм дәүләт хезмәте күрсәтү процессында мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәрге тәртиптә карау мөмкинлеге аша гамәлгә ашырыла.»;

5 бүлектә:

Исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт хезмәте күрсәтә торган органның, КФҮ, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законның 16 статьясының $1^1$ өлешендә күрсәтелгән оешмаларның, шулай ук аларның вазыйфаи затларының, дәүләт хезмәткәрләренең, хезмәткәрләрнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе»;

5.2 пунктының 1 пунктчасында «дәүләт хезмәте» сүзләреннән соң «210-ФЗ номерлы федераль законның $15^1$ статьясында күрсәтелгән гариза» сүзләрен өстәргә;

Регламентка 3 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Аз тәэмин ителгән гаиләдән балага
пособие билгеләү буенча дәүләт
хезмәте күрсәтүнең административ
регламентына 3 нче кушымта

форма

(Россия Федерациясе субъекты башкарма хакимиятенең вәкаләтле органы яисә җирле үзидарә органы исеме)

Кемгә _______________

Балага пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү турында карар

_________________ №___

___________ №_______ гаризаны һәм аңа теркәлгән документларны карау нәтиҗәләре буенча, ____________________________ нигезендә, аз тәэмин ителгән гаиләдәге балага пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү турында карар кабул ителде:

______________________________________

(Ф.И.А. (соңгысы – булган очракта), туу датасы)

__________ башлап __________ кадәр __________сум күләмендә

| Электрон имза турында мәгълумат |
|---|

Үрнәк

(Россия Федерациясе субъекты башкарма хакимиятенең вәкаләтле органы яисә җирле үзидарә органы исеме)

Кемгә

Балага пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар

_________________

№__________

__________№_________гаризаны һәм аңа теркәлгән документларны карау нәтиҗәләре буенча, ____________________ нигезендә, аз тәэмин ителгән гаиләдәге балага пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар кабул ителде, түбәндәге нигезләр буенча:

Хезмәт күрсәтүдән баш тарту сәбәпләрен аңлату:

Әлеге җитешсезлекләрне бетергәннән соң хезмәт күрсәтү турында гариза белән Сез вәкаләтле органга кабат мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Баш тарту турындагы әлеге карарга вәкаләтле органга шикаять җибәрү юлы белән – судка кадәрге тәртиптә, шулай ук суд тәртибендә дә, шикаять бирелергә мөмкин.

Электрон имза турында мәгълүмат

форма

(Россия Федерациясе субъекты башкарма хакимиятенең вәкаләтле органы яисә җирле үзидарә органы исеме)

Кемгә

Балага пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турында карар

__________ №__________

____________ №____________ гаризаны һәм аңа теркәлгән документларны карау нәтиҗәләре буенча, ________________ нигезендә, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турында карар кабул ителде, түбәндәге нигезләр буенча:

Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту сәбәпләрен аңлату:

Әлеге җитешсезлекләрне бетергәннән соң хезмәт күрсәтү турында гариза белән Сез вәкаләтле органга кабат мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Баш тарту турындагы әлеге карарга вәкаләтле органга шикаять җибәрү юлы белән – судка кадәрге тәртиптә, шулай ук суд тәртибендә дә, шикаять бирелергә мөмкин.

Электрон имза турында мәгълүмат »;

Регламентка 6 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Аз тәэмин ителгән гаиләдән балага пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 6 нчы кушымта

форма

«Матди ярдәм (компенсация түләүләре) республика үзәге» ДКУ №_____ бүлекчәсе

________________________________
муниципаль районында (шәһәр округында)

Балага айлык пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору турында карар

№______ «__» ________________

Мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта)
______________________________________________________________________________
Мөрәҗәгать итүченең адресы ______________________________________________

Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар һәм җыемнар буенча бурычлар булу сәбәпле, бурычларны түләп бетергәнчегә кадәр, балага пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатырга, ләкин дәүләт хезмәте күрсәтүне сорап мөрәҗәгать иткән көннән алып 90 көннән дә артыграк чорга түгел.

Бүлекчә җитәкчесе ________________________________________ _____________
(Фамилия, исем, ата исеме (соңгысы – булган очракта)) имза
мөһер урыны
Бүлекчә белгече ________________________________________ _____________
(Фамилия, исем, ата исеме (соңгысы – булган очракта)) имза
Мөрәҗәгать итүчегә хәбәр итү ысулы:
Язмача _______________________________________________
почта адресына
sms-хәбәр итеп ________________________________________
телефон №
электрон почта аша ____________________________________
Электрон почта адресы
Бүлекчә белгече ________________________________ __________________
(Фамилия, исем, ата исеме (соңгысы – булган очракта)) имза

«Матди ярдәм (компенсация түләүләре)
республика үзәге» ДКУ №_____бүлекчәсе
________________________________________
муниципаль районында (шәһәр округында)

Балага пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүне
яңарту турында карар

№_____ «__» ________________

Мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта)
______________________________________________________________________________
Мөрәҗәгать итүченең адресы ______________________________________________

Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар һәм җыемнар буенча бурычларны җайга салу белән бәйле рәвештә, балага пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүне «__» ________ башлап яңадан торгызырга.

Бүлекчә җитәкчесе ____________________________ ______________

(Фамилия, исем, ата исеме (соңгысы – булган очракта)) имза

Мөһер урыны

Бүлекчә белгече ______________________________ __________________

(Фамилия, исем, ата исеме (соңгысы – булган очракта)) имза

Мөрәҗәгать итүчегә хәбәр итү ысулы:

Язмача ____________________________________________________

почта адресына

sms-хәбәр итеп ______________________________________________

телефон №

электрон почта аша ________________________________________

Электрон почта адресы

Бүлекчә белгече ___________________________________ _____________

(Фамилия, исем, ата исеме (соңгысы – булган очракта)) имза».